**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**УТЫЗ СИГЕЗЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 5**

Акбаш тимер юл станциясе посёлогы «20» май 2019г

**Акбаш авыл җирлеге Советының**
**2019 елның 14 февралендә булып узган**
**XXXVII сессиясендә кабул ителгән**
**"Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы**
**"Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә**
**гавами тыңлаулар (җәмәгать тикшерүе)**
**оештыру һәм үткәрү тәртибе турында"гы**
**Нигезләмәне раслау хакында"гы 3нче карарга**
**үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып

**Акбаш авыл җирлеге Советы**
**КАРАР БИРДЕ:**

Акбаш авыл жирлеге Советының 2019 елның 14 февралендә булып узган XXXVII сессиясендә кабул ителгән "Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать тикшерүе) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында"гы Нигезләмәне раслау хакында"гы 3нче карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 4нче бүлектә:

*- 4нче пунктны яңа басмада бәян итәргә:*

«4. Гавами тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районы "Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы ("Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла.

Халык, Бөгелмә муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Акбаш авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы (“Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла торганы – “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Акбаш авыл җирлеге»**

**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Р.Т.Хужиев.**